**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Мәгълүмати куркынычсызлык буенча ведомствоара комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре турында» 2000 елның 6 июнендәге ПУ-394 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2000 елның 6 июлендәге ПУ-491 номерлы, 2000 елның 2 ноябрендәге ПУ-829 номерлы, 2002 елның 31 гыйнварындагы ПУ-65 номерлы, 2002 елның 15 ноябрендәге ПУ-992 номерлы, 2003 елның 1 апрелендәге ПУ-235 номерлы, 2003 елның 4 августындагы ПУ-563 номерлы, 2004 елның 10 мартындагы ПУ-163 номерлы, 2004 елның 21 июнендәге ПУ-461 номерлы, 2005 елның 28 маендагы ПУ-214 номерлы, 2005 елның 22 декабрендәге ПУ-513 номерлы, 2006 елның 18 февралендәге ПУ-64 номерлы, 2006 елның 18 маендагы ПУ-179 номерлы, 2007 елның 3 декабрендәге ПУ-646 номерлы, 2007 елның 25 декабрендәге ПУ-698 номерлы, 2008 елның 17 декабрендәге ПУ-660 номерлы, 2009 елның 3 июнендәге ПУ-318 номерлы, 2010 елның 4 февралендәге ПУ-42 номерлы, 2010 елның 21 июлендәге ПУ-475 номерлы, 2010 елның 9 декабрендәге ПУ-798 номерлы, 2012 елның 23 июнендәге ПУ-496 номерлы, 2012 елның 27 сентябрендәге ПУ-786 номерлы, 2012 елның 29 декабрендәге ПУ-1139 номерлы, 2013 елның 4 ноябрендәге ПУ-1072 номерлы, 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-910 номерлы, 2015 елның 31 июлендәге ПУ-691 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-34 номерлы, 2016 елның 15 ноябрендәге ПУ-1006 номерлы, 2017 елның 13 октябрендәге ПУ-909 номерлы, 2017 елның 7 ноябрендәге ПУ-986 номерлы, 2018 елның 16 маендагы ПУ-372 номерлы, 2018 елның 17 ноябрендәге ПУ-777 номерлы, 2019 елның 14 декабрендәге ПУ-747 номерлы, 2020 елның 23 июнендәге ПУ-360 номерлы, 2022 елның 26 июлендәге ПУ-498 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 28 июлендәге 518 номерлы һәм 2023 елның 21 ноябрендәге 795 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советының Мәгълүмати куркынычсызлык буенча ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан А.И. Афанасьевны, А.Г. Галимовны, Р.Ф. Мөбарәкшинны, Ю.С. Никитинны, А.Ф. Хәсьяновны, С.А. Этусны чыгарырга;

б) Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Гомзик Илья Александровичны – Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасарын;

Григорьева Елена Ивановнаны – Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручыны (килешү буенча);

Ильин Павел Андреевичны – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бүлекчәсе башлыгын (килешү буенча);

Королев Сергей Николаевичны – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының мәгълүмат-коммуникация технологияләрен хокук бозып куллануга каршы көрәшү бүлеге башлыгын (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

И.Р. Бегишевның – «Россия Федерациясе Федераль сак хезмәтенең Татарстан Республикасында махсус элемтә һәм мәгълүмат үзәгенең мәгълүмати-аналитик эш үзәге башлыгы урынбасары – үзәкнең 3 нче бүлекчәсе башлыгы (килешү буенча)»;

М.А. Большаковның – «Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бүлекчәсе башлыгы (килешү буенча)»;

А.А. Хәләповның – «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 06 март
№ 178